ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А. Медведевка үсемлекчелектә гадәттән тыш хәлләрне Россия Федерациясе территориясендә Сосновский балтырганы үсә торган урыннарны юкка чыгару өлешендә булдырмый калу буенча Россия Федерациясе дәүләт программасы эшләү кирәклеге турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А. Медведевка үсемлекчелектә гадәттән тыш хәлләрне Россия Федерациясе территориясендә Сосновский балтырганы үсә торган урыннарны юкка чыгару өлешендә булдырмый калу буенча Россия Федерациясе дәүләт программасы эшләү кирәклеге турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгатен кабул итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А. Медведевка җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының күрсәтелгән мөрәҗәгатен хуплауны сорап, Россия Федерациясе субъектлары закон чыгару (вәкиллекле) органнарына мөрәҗәгать итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2019 елның 14 феврале
№ 2724-V ДС

**Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А. Медведевка үсемлекчелектә гадәттән тыш хәлләрне Россия Федерациясе территориясендә Сосновский балтырганы үсә торган урыннарны юкка чыгару өлешендә булдырмый калу буенча Россия Федерациясе дәүләт программасын эшләү кирәклеге турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате**

Хөрмәтле Дмитрий Анатольевич!

Хәзерге вакытта Россия Федерациясе территориясендә Сосновский балтырганының күпләп таралуы җитди экологик куркынычлык тудыра. “Россельхозцентр” федераль дәүләт бюджет учреждениесе мәгълүматларына караганда, Россия Федерациясендә Сосновский балтырганы үсеп чыккан мәйдан 2017 елда 51 мең га булса, 2018 елда инде 80 га тәшкил иткән. Татарстан Республикасында балтырган 2017 елда 109 га мәйданда таралган булса, 2018 елда 536 га мәйданны каплаган.

Шуны билгеләп үтәргә кирәк: Сосновский балтырганы иң агрессив һәм башкалардан өстенлек ала торган чүп үләне булып тора, ул кешеләрнең һәм хайваннарның сәламәтлегенә зур зыян китерә. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы мәгълүматлары буенча, соңгы ике елда, балтырган тиеп, тәннәрендә җәрәхәтләр барлыкка килгән 480 кеше теркәлгән.

Моннан тыш, Сосновский балтырганы кырларда, юл кырыйларында, торак пунктларда, урманнарда, су буйларында үсеп чыга, кыйммәтле җир ресурсларын каплап китә һәм үсемлекләрне һәлак итә. Аны бетерү өчен агротехник, механик һәм химик ысуллардан гыйбарәт тулы бер чаралар комплексы таләп ителә. Сосновский балтырганына каршы көрәшне өзлексез рәвештә ул үсеп чыккан территориядә берничә ел дәвамында тулысынча беткәнче алып барырга кирәк. Шуңа күрә куркыныч үсемлеккә каршы көрәш проблемасы аеруча мөһим.

Хөрмәтле Дмитрий Анатольевич! Сездән үсемлекчелектә гадәттән тыш хәлләрне Россия Федерациясе территориясендә Сосновский балтырганы үсә торган урыннарны юкка чыгару өлешендә булдырмый калу буенча Россия Федерациясе дәүләт программасын эшләү йөкләмәсен бирүегезне үтенеп сорыйбыз.